Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

13 ноябрь 2020 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Чишмә поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, балигъ булган һәр кешедән 1000 сум (бер мең сум) күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Чишмә поселогы чикләрендә җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу;
- Чишмә бистәсендә су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х. Шәйхетдинов

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Р.Х. Шәйхетдинов